**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 8 февраль № 76

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив буенча финанслауны гамәлгә кертү турында» 2007 ел, 17 декабрь, 721 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 29 октябрь, 872 нче; 2011 ел, 13 май, 381 нче; 2011 ел, 20 сентябрь, 779 нчы; 2012 ел, 10 август, 675 нче; 2013 ел, 11 февраль, 89 нчы; 2013 ел, 24 сентябрь, 678 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Җирле үзидарә органнары өчен Татарстан Республикасында гомуми белем бирү учреждениеләре каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирүче интернат мәктәпләрдә мөлкәтне карап тоту нормативын исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрнең 3.12 нче пунктындагы өченче абзацта, 3.14 нче пунктындагы унбишенче абзацта тиешле килешләрдәге «план елы алдыннан килгән елның 1 сентябре хәленә, планлаштырылган чор инфляциясенең фараз дәрәҗәсенә индексланган» сүзләрен тиешле килешләрдәге «план елы алдыннан килгән елның 1 сентябре хәленә, чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Җирле үзидарә органнары өчен Татарстан Республикасында гомуми белем бирү учреждениеләре мөлкәтен карап тоту нормативын исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрнең 3.12 нче пунктындагы өченче абзацта, 3.14 нче пунктындагы уналтынчы абзацта тиешле килешләрдәге «план елы алдыннан килгән елның 1 сентябре хәленә, планлаштырылган чор инфляциясенең фараз дәрәҗәсенә индексланган» сүзләрен тиешле килешләрдәге «план елы алдыннан килгән елның 1 сентябре хәленә, чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Җирле үзидарә органнары өчен Татарстан Республикасында гомуми белем бирү учреждениеләре каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирүче интернат мәктәпләрдә тәрбияләнүчеләрне тәрбияләп тотуга финанс чыгымнары нормативын исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрдә:

исемдә «нормативын» сүзен «нормативларын» сүзләренә алмаштырырга;

2.9 нчы пунктның бишенче абзацында, 2.12 нче пунктның алтынчы абзацында, 2.19 нчы пунктның алтынчы абзацында, 2.27 нче пунктның җиденче абзацында тиешле килешләрдәге «план елы алдыннан килгән елның 1 сентябре хәленә, планлаштырылган чор инфляциясенең фараз дәрәҗәсенә индексланган» сүзләрен тиешле килешләрдәге «план елы алдыннан килгән елның 1 сентябре хәленә, чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив буенча финанслау турында» 2013 ел, 30 декабрь, 1096 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 25 июль, 546 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә финанс чыгымнар нормативларын исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрнең 3.1 нче пунктындагы өченче абзацта тиешле килешләрдәге «план елы алдыннан килгән елның 1 сентябре хәленә, планлаштырылган чор инфляциясенең фараз дәрәҗәсенә индексланган» сүзләрен тиешле килешләрдәге «план елы алдыннан килгән елның 1 сентябре хәленә, чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне караштырып тору һәм карау буенча хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрнең 2.20 нче пунктындагы дүртенче абзацта, 2.25 нче пунктындагы өченче абзацта, 2.28 нче пунктындагы өченче абзацта, 2.30 нчы пунктындагы өченче абзацта тиешле килешләрдәге «план елы алдыннан килгән елның 1 сентябре хәленә, планлаштырылган чор инфляциясенең фараз дәрәҗәсенә индексланган» сүзләрен тиешле килешләрдәге «план елы алдыннан килгән елның 1 сентябре хәленә, чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мөлкәтне карап тотуга норматив чыгымнарны, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә чыгымнарны, элемтә хезмәтләренә норматив чыгымнарны, бассейннарны карап тотуга норматив чыгымнарны исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрнең 1.3 нче пунктында 14 таблицадан соңгы җиденче абзацта, 3.1 нче пунктындагы өченче абзацта тиешле килешләрдәге «план елы алдыннан

килгән елның 1 сентябре хәленә, планлаштырылган чор инфляциясенең фараз дәрәҗәсенә индексланган» сүзләрен тиешле килешләрдәге «план елы алдыннан килгән елның 1 сентябре хәленә, чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекс-дефляторларны исәпкә алып» сүзләренә алмаштырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\76.doc